| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** — Казан ш. — **БОЕРЫК**

16.07.2013 — № 2179-р

**Россия Федерациясе гражданнарына үзләре били торган, Татарстан Республикасының казна мөлкәте булып торган торагын милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

1. Россия Федерациясе гражданнарына үзләре били торган, Татарстан Республикасының казна мөлкәте булып торган торагын милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең беркетелгән административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга

2. Министр урынбасарларына, идарә башлыкларына хезмәткәрләрне регламент белән таныштыруны оештырырга һәм тайпылышсыз үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның башкарылуын контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары С.А.Демидовка йөкләргә.

Министр
А.К.ХАМАЕВ

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының
16 июля 2013 г. N 2179-р
карары белән расланган

**Россия Федерациясе гражданнарына үзләре били торган, Татарстан Республикасының казна мөлкәте булып торган торагын милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

1. Гомуми нигезләмләр

1.1. Әлеге Регламент Россия Федерациясе гражданнарына үзләре били торган, Татарстан Республикасының казна мөлкәте булып торган торагын милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартларын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: Татарстан Республикасының казна мөлкәте булып торган торакларын социаль найм шартларында биләүче Россия Федерациясе гражданнары (алга таба – гариза бирүче).

1.3. Дәүләт хезмәтен Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – Министрлык) күрсәтә.

1.3.1. Место нахождения Министерства: г. Казань, ул. Вишневского, д. 26.

График работы Министерства: ежедневно, кроме субботы и воскресенья, понедельник - четверг с 9.00 до 18.00, пятница с 9.00 до 16.45, обед с 11.45 до 12.30.

Министрлыкның урнашкан урыны: Казан ш., Вишневский ур., 26 й.

Министрлыкның эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00дән 18.00гә кадәр, җомга – 9.00дән 16.45кә кадәр, төшке аш 11.45тән 12.30га кадәр.

Гариза бирүчеләрдән мөрәҗәгатьләр алдан язылып “Гражданнарны кабул итү” кабинетында башкарыла.

- сишәмбе 15.00 - 17.00 (документлар кабул итү);

- чәршәмбе 9.30 - 11.30 (документлар кабул итү);

- пәнҗешәмбе 9.30 - 11.30 (документлар кабул итү);

- җомга 14.00 - 16.00 (шартнамәләр тапшыру).

Кабул ителүгә телефон аша языласы: __________

Пропуск һәм шәхесне раслаучы документ белән керергә.

Җәмәгать транспортында:

1, 4, 25, 43 маршруты автобуслары белән “Калинин” тукталышына кадәр барырга;

метро станциясе – “Сукно бистәсе”.

1.3.2. Министрлыкның Мөлкәт идарәсе Торак күчемсез мөлкәт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары бүлегенең белешмә телефоннары (алга таба – Бүлек): 221-40-86, 221-40-28.

1.3.3. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендәге (алга таба – Интернет челтәре) рәсми сайты адресы: http://www.mzio.tatarstan.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәгечә алып була:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст рәвешендәге мәгълүматны эченә алган дәүләт хезмәте турында Министрлык эчендә урнаштырылган мәгълүмат стендларыннан;

2) “Интернет” челтәре ярдәмендә:

Министрлыкның “Интернет” челтәрендәге рәсми сайтыннан (алга таба – рәсми сайт) (http://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru);

Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.tatar.ru);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать итеп (шәхсән яки телефоннан);

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать итеп.

1.3.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләләре турында мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтына һәм, гариза бирүчеләр белән эшләү өчен, Министрлык бинасындагы мәгълүмат стендларына урнаштырыла.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә хәл ителә:

Россия Федерациясе Конституциясе (РФ законнары җыелмасы, 26.01.2009, N 4, ст. 445);

Россия Федерациясе Торак кодексы (алга таба – РФ ТК) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, № 1, 14 ст.);

«Россия Федерациясендә торак фондын приватизацияләү турында» 04 июль, 1991 ел, № 1541-1 Россия Федерациясе Законы (алга таба – Закон № 1541-1) (Норматив актлар бюллетене, 1992);

“Күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-биреш итүгә хокукларны дәүләт теркәвенә алу турында” 21.07.1997, № 122-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 122-ФЗ Федераль закон) (РФ законнары җыелмасы, 28.07.1997, № 30, ст. 3594);

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында” 27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ Федераль закон) (РФ законнары җыелмасы, 02.08.2010 ел, № 31, 4179 ст.);

Татарстан Республикасы Конституциясе (Республика Татарстан, N 87-88, 30.04.2002);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре” 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 03.10.2007, № 37, 1379 ст.);

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 880 ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, № 46, 2144 ст.);

“Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеген раслау турында” 13.08.2011, № 675 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 675 ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма

хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 19.10.2011, № 39, 1928 ст.);

2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка таләпнең эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | Россия Федерациясе гражданнарына үзләре били торган, Татарстан Республикасының казна мөлкәте булып торган торагын милеккә тапшыру | РФ ТК;<br>РФ Законы № 1541-1;<br>Нигезләмә 3.3.58. п. |
| 2.2. Башкарма хакимиятнең дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче органы атамасы | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе тасвирламасы | Торакны граждан милке итеп бирү турында Министрлык карары (алга таба – Министрлык карары).<br>Торакны граждан милке итеп бирү шартнамәсе (алга – Шартнамә).<br>Торакны граждан милке итеп бирүдән баш тарту | РФ ТК;<br>РФ Законы № 1541-1;<br>Нигезләмә 3.3.58. п. |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы | Дәүләт хезмәте гариза кергән көннән башлап ике ай эчендә күрсәтелә. | РФ Законы № 1541-1, 8 ст. |
| 2.5. Дәүләт хезмәте, шулай ук гариза бирүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган | Торакны граждан милке итеп бирү турында карар кабул итү өчен дәүләт хезмзте алучы (гариза бирүче) торакны гражданга милек итеп бирү турында гариза (1 нче кушымта) <1> белән бергә түбәндәгеләрне тапшырырга | РФ Законы № 1541-1; |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | тиеш:<br>1. 14 яше тулган һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге гаилә әгъзаларының паспорт күчермәсе (шәхесне аныклаучы башка документлар).<br>2. Торакны биләүченең 14 яше тулмаган гаилә әгъзаларының туу турында таныклык күчермәсе.<br>3. Гражданнарның торактан файдалану хокукын раслаучы документ.<br>4. Гражданның элегрәк, 1991 елның 4 июленнән соң, даими яшәгән урыннарыннан (андый мәгълүмат паспортта булмаса) йорт кенәгәсе өземтәсе.<br>5. Элек яшәгән урыннарда түләүсез приватизация хокукын файдаланмау турында 2000 елның 1 январена кадәр Россия Федерациясе территориясендә күчемсез милеккә хокукларны теркәү эшен башкарган вәкаләтле органнан Россия Федерациясе субъекты территориясендәге законнар таләпләренә туры китереп бирелгән справка (гариза бирүче Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшәгән очракта – “Казан шәһәренең муниципаль торак программалары дирекциясе” муниципаль унитар предприятиесеннән Казан шәһәрендә торакны приватизацияләүдә катнашмау (катнашу) турында белешмә).<br>7. Опекун, попечитель билгеләү турында карар, опекун | |

| | | |
|---|---|---|
| | таныклыгы күчермәсе, опека һәм попечительлек органнарыннан торакны приватизацияләргә рөхсәт кәгазе – 14 яше тулмаган балигъ булмаган балалар, үзен-үзе карарга сәләтсез гражданнар гына яшәгән торак приватизацияләнгәндә.<br>8. Ата-ананың (уллыкка алучыларның), попечительләрнең һәм опека һәм попечительлек органнарының торакны приватизацияләргә рөхсәт кәгазе, торакта 14-18 яшьлек балигъ булмаган балалар, яисә үзен-үзе карау сәләте чикле гражданнар яшәсә, опекунлык таныклыгы күчермәсе.<br>9. Мөрәҗәгать ышанычнамә буенча тутырылганда вәкаләтле зат паспортын (шәхесне таныклаучы башка документ), нотариус раслаган ышанычнамәне, яисә законнар буенча нотариус тарафыннан расланганга тәңгәлләштерелгән ышанычнамәне күрсәтә<br>Торакны гражданнарның милкенә бирә турында мөрәҗәгатькә теркәлгән документ күчермәләре нотариуста раслана ала. Нотариус раслаган күчермәләр булмаган очракта, түбәндәгеләр кабул ителә:<br>дөреслеге җитәкче яисә вазыйфаи затны вәкаләтләре булган зат имзасы һәм оешма мөһере (булса) белән расланган документлар күчермәләре;<br>документның төп нөсхәсе күрсәтелү шарты белән | |

| | | |
|---|---|---|
| | расланмаган документлар. Бу очракта документны кабул итүче документның күчермәсен аның төп нөсхәсе белән чагыштыра.<br>Торакны биләп торучы гаиләсендәге бер яки берничә әгъза торакны приватизацияләүдә катнашудан баш тартса, гариза (2нче кушымта), яисә торакның приватизацияләнүенә ризалыгы турында нотариуста расланган ризалык белдерүе, яисә законнар буенча нотариуста расланганга тигезләштерелгән ризалык белдерүе бирелә. | |
| 2.6. Норматив хокукый актларга туры китереп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм башка оешмаларда сакланган, гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүченең аларны алу ысуллары, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар сакланган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | 1. Күчемсез милеккә хокуклар һәм аның белән алыш-биреш бердәм дәүләт реестрыннан алга таба – ЕГРН) өземтә:<br>- аерым затның үзендә булган күчемсез милек объектына хокуклар турында;<br>- күчемсез милеккә хокуклар күчүе турында.<br>2. Торакның кадастр паспорты | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү өчен таләп ителгән һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма орган тарафыннан тормышка ашырыла торган норматив-хокукый актларда каралган очракларда килештерү зарури булган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | ителми | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | Гариза һәм аңа беркетелгән документлар турыдан туры Бүлеккә тапшырылганда:<br>1. Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның тулы комплекты бирелмәгән.<br>2. Гаризада һәм (яки) аңа беркетелгән документларда төрлечә аңлауга китерүче чистартулар, өстәп язулар булу.<br>3. Дәүләт хезмәте күрсәтү үтенече белән әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгате. | РФ законы 04.07.1991 N 1541-1 |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>1. Законнар буенча билгеләнгән белешмәләрнең булмавы яисә гариза бирүче тапшырган документларда дөреслеге расланмаган белешмәләр булуы; | РФ законы 04.07.1991 N 1541-1 |

| | | |
|---|---|---|
| | 2. тапшырылган документларның әлеге Регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;<br>3. торакның түбәндәге очракларында:<br>тузган торак халәтендә;<br>тулай торак<br>4. хезмәт вазыйфасы белән бәйле торак<br>5. гариза бирүче элегрәк торакны приватизацияләүдә катнашкан, № 1541-1 Законның 11 статьясында күрсәтелгән очрак искәрмә булып тора;<br>6. торак Татарстан Республикасы казнасы составына керми;<br>7. торак кадастр исәбенә куелмаган | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләүнең тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә | РФ законы 04.07.1991 N 1541-1 |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы алынучы түләүләрнең тәртибе, күләме һәм нигезләре, андый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы | Торак кадастр исәбенә техник инвентаризацияне һәм объектны кадастр исәбенә куючы органнар өчен билгеләнгән тариф буенча куела. | Карар КМ РТ N 675 |

| | | |
|---|---|---|
| мәгълүматны да кертеп | | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәтләрне күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы | Дәүләт хезмәте алучының (гариза бирүченең) кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтүенең һәм дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәтен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап гариза бирүченең запросын рәсмиләштерү срогы | Мөрәҗәгать кергән бер көн эчендә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә таләпләр | Мөрәҗәгать Министрлыкка 420043, Казан ш., Вишневский ур., 26 й. адресы буенча бирелә (юллана).<br>Дәүләт хезмәтләре күрсәтелү тиешле күрсәткечләр белән җиһазланган бүлмәләрдә башкарыла.<br>һаваны суыту-җылыту системасы;<br>янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы;<br>документлар тутыру өчен җиһаз;<br>Татарстан Республикасы Дәүләт интеграцияләнгән телекоммуникация системасына тоташтырылган мәгълүмати киоск;<br>мәгълүмати стенд.<br>Дәүләт хезмәте күп функцияләр башкаручы үзәктә күрсәтелми. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем | Дәүләт хезмәтенең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән | |

| | | |
|---|---|---|
| өчен ачык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре | гыйбарәт:<br>- документларны кабул итү һәм карау срогының саклануы;<br>- Регламентның дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан бозылуын күрсәткән очракларның (нигезләнгән шикаятьләрнең) булуы (очраклар, шикаятьләр санының хезмәт күрсәтүче Министрлык белгечләренең гомуми санына чагыштырмасы).<br>Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>- Министрлык биналарының җәмәгать транспортына якын булуы;<br>- кирәк кадәр санда белгечләрнең, шулай ук, гариза бирүчеләрнең документларын кабул итә торган урыннарның булуы;<br>- мәгълүмати стендларда һәм “Интернет” челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында дәүләт хезмәте күрсәтүнең ысуллары, тәртибе һәм вакыты турында тулы мәгълүмат булу | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтелми | |

--------------------------------

<1> Киңәш ителгән форма.

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларның (гамәлләрнең) электрон рәвештә үтәлүе үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм регистрация;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллау;

4) Министрлык карары әзерлә\ һәм кабул итү яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр (баш тарту турында хәбәр) әзерләү, Шартнамә әзерләү;

5) Шартнамәне имзалау һәм регистрацияләү;

6) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы 4 нче кушымтада китерелә.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү.

Гариза бирүче, дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен, Бүлеккә шәхсән, телефоннан, һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итүгә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә тапшырылырга тиешле документларның составы, формасы ягыннан һәм дәүләт хезмәте алуга карата башка мәсьәләләр буенча консультация бирә

Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән алдан сканер аша үткәрелгән документлар пакетын составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультация алу өчен Бүлеккә  почта аша юлларга мөмкин.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне үтәлә, документлар пакеты электрон почта аша юлланса, документлар җибәрелгән көнне дә кертеп өч көндә анализ ясала.

Процедура нәтиҗәсе: документациянең составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультация.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм регистрацияләү

3.3.1. Гариза бирүче (аның вәкиле) әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар беркетелгән мөрәҗәгатен Бүлеккә бирә яки күрсәтелгән документларны почта аша юллый.

3.3.2. Бүлек белгече гариза һәм документлар Бүлеккә тапшырылса:

вәкилнең вәкаләтләрен (боерык, ышанычнамә һ.б.) тикшерә;

гаризаны һәм документларны кабул итә;

гариза бирүченең шәхесен ачыклый, шәхесне ачыклый торган документны тикшерә;

әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булу-булмавын тикшерә, түбәндәгеләрне ачыклый:

- документлар расланган, мөһер сугылган, законнарда билгеләнгән вазыйфаи затларның имзасы бар;

- документларның тексты танырлык итеп язылган, юридик зат атамалары кыскартмыйча бирелгән, урнашкан урыны күрсәтелгән;

- документларда чистартылган, өстәп язылган урыннар юк, сүзләр сызылмаган, алдан килештерелмәгән төзәтүләр кертелмәгән;

- документлар карандаш белән тутырылмаган;

- документларда аларның эчтәлеген төрлечә аңларга мөмкинлек бирә торган зарарланган урыннар юк.

Гариза бирүченең документ күчермәләре расланмаган булса, әлеге күчермәләр тапшырылганда төп нөсхә дә күрсәтелә һәм алар Бүлек белгече тарафыннан раслана.

Гариза бирүче документларның тулы комплектын тапшырмаса, шулай ук, техник хаталар булган яки аларны формалаштыру алда күрсәтелгән таләпләргә туры килмәсә, Бүлек белгече дәүләт хезмәтен гамәлгә ашыру өчен каршылыклар булуын хәбәр итә, тапшырылган документларда ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, документларда ачыкланган җитешсезлекләрне төзәтү максатыннан чаралар күрү өчен кире кайтара.

Бүлек белгече бирелгән документларны тикшергәч түбәндәгеләрне башкара:

- гариза кабул ителү турында гаризалар кабул итү һәм торакны приватизацияләү буенча документлар тапшыру кенәгәсенә язып куя яисә кабул итүдән баш тарту турында яза (язуының тәртип номеры, кабул итү датасы һәм минутына кадәр төгәллек белән вакыты, документларның гомуми саны, гариза бирүче турында мәгълүмат, гариза бирүченең мөрәҗәгате максаты, документларны кабул итүдән баш тарту сәбәбе, үз фамилиясе һәм инициаллары);

- гаризага беркетелгән документларның исемлеген ике экземплярда әзерли, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

- документлар кабул иткән һәм гариза бирүчеләр теркәлә торган кенәгәне тутырган, имзасын куйган белгечнең фамилиясе һәм инициаллары;

- гариза бирүченең фамилиясе һәм инициаллары, шулай ук, имзасы;

гариза бирүчегә гариза теркәлгән документлар исемлегенең бер экземпляры тапшырыла;

гаризаны һәм документларны һәм гаризага теркәлгән документлар исемлегенең икенче экземплярын регистрация өчен Министрлыкның эш башкару һәм контроль бүлегенә (алга таба – эш башкару бүлеге) юллау.

Процедураның нәтиҗәсе: тикшерелгән һәм эш башкару бүлегенә юлланган гариза һәм документлар; документларны кабул итүдән баш тарту.

3.3.3. Эш башкару бүлеге белгече гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны алганнан соң, шулай ук, алар почта аша керсә дә, гаризаны һәм документларны регистрацияли, керү номеры суга һәм карау өчен Бүлеккә юллый.

Әлеге Регламентның 3.3.2 – 3.3.3 пунктлары билгеләгән процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Бүлеккә юлланган үтенечнамә һәм беркетелгән документлар.

3.4. Бүлек белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон формада түбәндәге запросларны юллый:

аерым затның үзендә булган күчемсез милек объектына хокуклар турында ЕГРПтан өземтә - Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенә (алга таба – ТР буенча Росреестр);

күчемсез милеккә хокуклар күчүе турында өземтә - ТР буенча Росреестрга.

Туракның кадастр паспортын бирү турында - Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе филиалына (ТР буенча ФКП Росреестр филиалы).

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң җиде көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүматлар (документлар) бирү турындагы запрослар

3.5. Бүлек белгече әлеге Регламентның 3.4 пунктына туры китереп юлланган запросларга ТР Росреестрдан, ТР буенча ФКП Росреестр филиалыннан соралган белешмәләр алынгач, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарта торган Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Баш тарту турында хәбәр 3 нче кушымта үрнәгендә формалаштырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң ун көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек белгеченең документларга экспертиза ясавы.

3.6. Кергән документларга экспертиза ясагач, Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

Министрлык карары проектын һәм Шартнамә проектын яисә гариза бирүчедән кергән документлар нигезендә торакны гражданга милеккә биреп булмау сәбәпләрен аңлатып һәм ачыкланган җитешчезлекләрдән котылу юлларын тәкъдим итеп баш тарту турында карар проектын әзерли;

Министрлык карары проектын һәм Шартнамә проектын яисә баш тарту турында карар проектын килештерү өчен Бүлек мөдиренә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң тугыз көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: килештерү өчен Бүлек мөдиренә юлланган Министрлык карары проекты һәм Шартнамә проекты яисә баш тарту турында карар проекты.

3.7. Бүлек мөдире Министрлык карары проектын һәм Шартнамә проектын яисә баш тарту турында карар проектын карый, килештерә һәм килештерү өчен Мөлкәт идарәсе (алга таба – Идарә) башлыгына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: килештерү өчен идарә башлыгына юлланган Министрлык карары проекты һәм Шартнамә проекты яисә баш тарту турында карар проекты.

3.8. Идарә башлыгы Министрлык карары проектын һәм Шартнамә проектын яисә баш тарту турында хәбәр проектын карый, килештерә һәм Бүлек белгеченә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Идарә башлыгы белән килештерелгән Министрлык карары проекты һәм Шартнамә проекты яисә баш тарту турында хәбәр проекты.

3.9. Бүлек белгече Министрлык карары проектын һәм Шартнамә проектын яисә баш тарту турында карар проектын хокукый экспертиза өчен хокук идарәсенә юллый

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура Идарә башлыгы Министрлык карары проектын һәм Шартнамә проектын яисә баш тарту турында хәбәр проектын килештергән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Хокук идарәсенә юлланган Министрлык карары проекты һәм Шартнамә проекты яисә баш тарту турында хәбәр проекты.

3.10. Хокук идарәсе белгече Министрлык карары проектына һәм Шартнамә проектына яисә баш тарту турында хәбәр проектына экспертиза ясый килештерү өчен хокук идарәсе башлыгына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң ун көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Министрлык карары проектына хокук идарәсе бәяләмәсе яисә килештерелгән Министрлык карары проекты яисә килештерелгән баш тарту турында хәбәр проекты.

3.11. Хокук идарәсе башлыгы бәяләмәне яисә Министрлык карары проектын яисә баш тарту турында хәбәр проектына килештерә һәм Бүлек белгеченә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: хокук идарәсе бәяләмәсе яки килештерелгән Министрлык карары проектын яисә килештерелгән баш тарту турында хәбәр проекты.

3.12. Бүлек белгече министрның беренче урынбасарына килештерү өчен Министрлык карары проектын яки баш тарту турында хәбәр проектын имза куярга юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: министрның беренче урынбасарына килештерү өчен юлланган Министрлык карары проекты яисә имза куярга юлланган баш тарту турында хәбәр проекты.

3.13. Министрның беренче урынбасары Министрлык карары проектын килештерә һәм министрга имза кую өчен юллый яисә баш тарту турында хәбәрне имзалый һәм теркәү өчен эш башкару бүлегенә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: килештерелгән һәм имза кую өчен минитсрга юлланган Министрлык карары проекты яки имзаланган һәм регистрацияләү өчен Эш башкару бүлегенә юлланган баш тарту турында хәбәр.

3.14. Министр Министрлык карары проектына кул куя һәм эш башкару бүлегенә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: министр имзалаган һәм Эш башкару бүлегенә юлланган Министрлык карары.

3.15. Эш башкару бүлеге белгече Министрлык карарын терки һәм гариза бирүчегә тапшыру өчен Бүлек белгеченә бирә яисә баш тарту турында хәбәрне гариза бирүче күрсәткән почта адресына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: регистрацияләнгән һәм гариза бирүчегә тапшыру өчен Бүлек белгеченә бирелгән Министрлык карары яки регистрацияләнгән һәм гариза бирүчегә юлланган бавш тарту турында хәбәр.

3.16. Министрлык карары кабул ителсә, Бүлек белгече министр урынбасарына кул кую өчен Шартнамәне җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: министр урынбасарына кул кую өчен юлланган торакны гражданга милек итеп бирүгә шартнамә.

3.17. Министрның беренче урынбасары Шартнамәне имзалый һәм Бүлек белгеченә регистрациягә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: имзаланган һәм Бүлек белгеченә регистрациягә юлланган шартнамә.

3.18. Бүлек белгече шартнамә регистрацияли һәм гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алырга килү өчен билгеләнгән дата һәм вакыт турында хәбәр итә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: регистрацияләнгән шартнамә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алырга килү өчен билгеләнгән дата һәм вакыт турында хәбәр ителгән гариза бирүче.

3.19. Гариза бирүче билгеләнгән вакытта Министрлыкка Министрлык карарын һәм Шартнамәне алырга килә.

Әлеге процедура башкарылганда Бүлек белгече гариза бирүчегә Шартнамәнең ТР буенча Росреестрда теркәлергә тиешлеген хәбәр итә.

Әлеге пункт билгели торган процедура гариза бирүче килгән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән Министрлык карары һәм Шартнамә.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеге саклануын дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Идарә (бүлек) җитәкчесе әлеге Регламент нигезләмәләрен үтәү һәм башкаруны күзәтү юлы белән контрольдә тота.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәге тикшерүләр тора:

- хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларына экспертизалар үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларга виза салу тора;

- тиешле тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү;

Бүлектә эш башкаруны алып баруны тикшерүләр үткәрү.

Тикшерүләр планлы (Министрлыкның эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Планлы тикшерүләр үткәргәндә хезмәт күрәстүгә бәйле барлык сораулар карала (комплекслы тикшеренүләр), яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген контрольдә тоту дәүләт хезмәте күрсәтүне оештыру эше өчен җаваплы министр урынбасары, эш башкару бүлеге белгечләре, шулай ук, Министрлыкның имәп, мониторинг һәм мәгълүмати арадашлык идарәсенең Туплау бүлеге белгечләре тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне башкаручы вазыйфаи затлар Министрлыкның структур бүлекчәләре турында нигезләмәләр, вазыйфаи регламентлар белән гамәлгә ашырыла.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законы нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Регламент үтәлешен граждannар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан контрольдә тоту Министрлыкка мөрәҗәгатьләр юллау, шулай ук, Регламент үтәлеше барышында кылган (кылмаган) гамәлләре турында шикаятьләр белән дәүләт хакимиятенең югарырак органнарына мөрәҗәгатьләр аша гамәлгә ашырыла.

5. Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү

5.1. Гариза бирүчеләр Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә карата шикаять белдерүгә хокуклы.

5.2. Шикаять язмача кәгазьдә яисә электрон формада Министрлыкка бирелә.

Министрның карарларына шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә

5.3. Шикаять почта аша, МФЦ аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып Министрлыкның рәсми сайты, Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталы яисә Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка

норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

5.5. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш::

1) карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять белдерелгән Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булганда), яшәү урыны турында мәгълүматлар, мөрәҗәгать итүче юридик затның урнашкан урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүченең Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре белән килешмәвенә дәлилләре. Гариза бирүче үз дәлилләрен раслый торган документлар (булганда) яки аларның күчермәләрен тапшыра ала.

5.6. Министрлыкка кергән шикаять шикаятьләрне карап тикшерүгә вәкаләте булган вазыйфаи зат тарафыннан шикаять теркәлгән көннән алып унбиш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш, Министрлык, аның вазыйфаи заты гариза бирүчедән документларын кабул итеп алудан баш тартуга яки ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуга яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять белдерелгән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.7. Министрлык шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан кабул ителгән карарны юкка чыгару рәвешендә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда Министрлык тарафыннан җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акча средстволарын гариза бирүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

5.8. Әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм, гариза бирүченең теләгенә карап, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.9. Шикаятьләрнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында карап тикшерү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

Россия Федерациясе гражданнарына үзләре били торган, Татарстан Республикасының казна мөлкәте булып торган торагын милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына
________________________________________
(Фамилия, Инициаллар)

(кемнән) ______________________________________
(Фамилия, Инициаллар)

______________________________________________
____________________________ адресы буенча яшәүче

тел. ____________________________________________

ГАРИЗА
(якынча үрнәге)

гр.________________________________________________________________,
(приватизациядә катнашучы гражданның Ф.И.Әи.)

гр.____________________________________________________________ и т. д.
Республика Татарстан, ____________ шәһәре, _________________ урамы, _______ номерлы йорт, корпус № (литер) ______, фатир (бүлмә) ___________ адресы белән урнашкан без (мин) биләп торган торакны – ________ бүлмәле фатирны (бүлмә(ләр)не (кирәгенең астына сызарга)
__________________________________________ милек итеп бирүегезне сорыйм
(кирәк булса, милек төрен күрсәтергә: гомуми, гомуми өлешле)

Әлеге гариза белән 420043, ТР, Казан ш., Вишневский ур., 26 й. адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына (оператор) “Персональ мәгълүматлар турында” 27.07.2006 ел, №152-ФЗ Федераль законның 3 ст. 1 1 кисәгенең 3 п.да каралган гамәлләрне автоматлаштырылган, шулай ук, автоматлашытырлагн эшкәртү чараларны кулланмыйча персональ мәгълүматны эшкәртергә рөхсәт бирәм.

Мәгълүматның дөреслеген өчен җаваплылык турында кисәтелгән.

Әлеге килешү гариза имзаланган көннән башлап язма рәвештә килешүне кире соратып алган көнгә кадәр гамәлдә була.

________________________________

____________________________________ _____________________________________

(фамилия, исем, әтисе исеме) (имза, дата)

## Биләп торган торакны приватизацияләргә рөхмәт бирүләрен раслаган гаилә әгъзаларының составы һәм имзалары, персональ мәгълүматны эшкәртүгә рөхсәтләре:

| N п/п | Ф.И.Әи. (тутырып) РФ Хәрби көчләре сафларында хезмәт итүчеләрне дә, командировкадагыларны да, ирегe чикләнгәннәрне һ.б. исәпкә алып | Туган көне (көне, ае, елы) | Туганлык мөнәсәбәтләре | Паспорт мәгълүматлары, туу турында таныклыклар (серия, номер, кем һәм кайчан тапшырган, подразделение коды) | Теркәү датасы | Өлеш күләме | 14 яше тулган һәм аннан өлкәнрәк гаилә әгъзаларының имзалары |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1 | | | Биләүче | | | | |
| 2 | | | | | | | |
| 3 | | | | | | | |

Искәрмә:
1. 8 нче графа торакны гомуми өлешле милеккә алганда тутырыла.
2. 14 яше тулмаган балалар өчен ата-ананың берсе, опекуны имза куя.
3. 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган балалар ата-ананың берсенең, опекунның, попечительнең ризалыгы белән имза куя. Ата-ананың, опекунның, попечительнең ризалыгы имза белән раслана.

Мөрәҗәгать кабул ителде «______» ___________ 20___ ел. Һәм Торакны приватизацияләү буенча документлар кабул итү һәм бирүне исәпкә алу кенәгәсендә _____ номеры белән теркәлде.
Гариза бирүчеләрнең мәгълүматы тикшерелде һәм шәхесне раслаган документларда күрсәтелгәнгә туры килә _____________________________________

____________________________________________________________________________________________

(хезмәткәрнең фамилиясе, инициаллары) (имза)

Россия Федерациясе гражданнарына үзләре били торган, Татарстан Республикасының казна мөлкәте булып торган торагын милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

Искәрмә:
1. 8 нче графа торакны гомуми өлешле милеккә алганда тутырыла.
2. 14 яше тулмаган балалар өчен ата-ананың берсе, опекуны имза куя.
3. 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган балалар ата-ананың берсенең, опекунның, попечительнең ризалыгы белән имза куя. Ата-ананың, опекунның, попечительнең ризалыгы имза белән раслана.

Мөрәҗәгать кабул ителде «______» __________ 20___ ел. Һәм Торакны приватизацияләү буенча документлар кабул итү һәм бирүне исәпкә алу кенәгәсендә _____ номеры белән теркәлде.
Гариза бирүчеләрнең мәгълүматы тикшерелде һәм шәхесне раслаган документларда күрсәтелгәнгә туры килә ________________________________

________________________________________________________________________
(хезмәткәрнең фамилиясе, инициаллары) (имза)

Әлеге гариза белән 420043, ТР, Казан ш., Вишневский ур., 26 й. адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына (оператор) “Персональ мәгълүматлар турында” 27.07.2006 ел, №152-ФЗ Федераль законның 3 ст. 1 1 кисәгенең 3 п.да каралган гамәлләрне автоматлаштырылган, шулай ук, автоматлашытырлагн эшкәртү чараларны кулланмыйча персональ мәгълүматны эшкәртергә рөхсәт бирәм.

Мәгълүматның дөреслеген өчен җаваплылык турында кисәтелгән.

Әлеге килешү гариза имзаланган көннән башлап язма рәвештә килешүне кире соратып алган көнгә кадәр гамәлдә була.

Дата ____________________________ Имза ________________________________________

Россия Федерациясе гражданнарына үзләре били торган, Татарстан Республикасының казна мөлкәте булып торган торагын милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

гражданинга _______________________________,
(фамилия, инициаллар)
урам___________,. ___, кв. (ком.) ____,
шәһәр _____________, индекс _______________


Дәүләт хезмәте баш тарту турында хәбәр
(үрнәк форма)

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Сезнең гаризаны һәм тапшырылган документларны карап, Татарстан Республикасы, шәһәр _____________, урам _______________________, йорт N _________, корпус N (литер) ____________, фатир (бүлмә) N ____________, адресы буенча урнашкан торакны сезгә милеккә бирүдән түбәндәге нигезләрдән чыгып баш тарта:
_____________________________________________________________________________
(законнар буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре күрсәтелә)
_____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________.

___________________________ (вазыйфа) (имза) ________________________________ (инициаллар, фамилия)

Россия Федерациясе гражданнарына үзләре били торган, Татарстан Республикасының казна мөлкәте булып торган торагын милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
4 нче кушымта

**Россия Федерациясе гражданнарына үзләре били торган, Татарстан Республикасының казна мөлкәте булып торган торагын милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы**



Бүлек белгече

Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы белән килештерелгән торакны бирү турында карар проектын, торакны бирү шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын хокукый экспертизага юллый

Хокукый экспертизага юлланган торакны бирү турында карар проектын, торакны бирү шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проекты

Хокук идарәсе белгече

Торакны бирү турында карар проектына, торакны бирү шартнамәсе проектына яисә баш тарту турында карар проектына хокукый экспертиза (шул исәптән, коррупциягә каршы экспертиза) ясый

Килештерелгән торакны бирү турында карар проекты, торакны бирү шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты яки хокук идарәсе бәяләмәсе

Хокук идарәсе башлыгы

Торакны бирү турында карар проектын, торакны бирү шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын килештерә яки Хокук идарәсе бәяләмәсенә кул куя

Килештерелгән торакны бирү турында карар проекты, торакны бирү шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты

Хокук идарәсе бәяләмәсе

Бүлек белгече

Хокук идарәсе бәяләмәсендә күрсәтелгән кимчелекләрне бетерә һәм торакны бирү турында карар проектын, торакны бирү шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын килештерү өчен хокук идарәсенә юллый

Килештерү өчен хокук идарәсенә юлланган торакны бирү турында карар проекты, торакны бирү шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты

Хокук идарәсе башлыгы

Торакны бирү турында карар проектын, торакны бирү шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын килештерә

Килештерелгән торакны бирү турында карар проекты, торакны бирү шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты

Бүлек белгече


Торакны бирү турында карар проектын, торакны бирү шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын министрның беренче урынбасарына юллый

Имза куюөченминистрның беренче урынбасарына юлланган торакны бирү турында карар проекты, торакны бирү шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты

Министрның беренче урынбасары

Торакны бирү турында карарга, торакны бирү шартнамәсе проектына яисә баш тарту турында карар проектына кул куя һәм теркәү өчен эш башкару бүлегенә юллый

Имзаланган торакны бирү турында карар, торакны бирү шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты


Эш башкару бүлеге белгече
Торакны бирү турында карарны, торакны бирү шартнамәсе проектына яисә баш тарту турында карарны терки. Торакны бирү турында карар Бүлеккә юллана.
Гариза бирүчегә юлланган торакны бирү шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар
Бүлеккә юлланган торакны бирү турында карар
Эш башкару бүлеге белгече
Гариза бирүчегә торакны бирү шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карарны бирә
Гариза бирүчегә тапшырылган торакны бирү шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар
Заявитель
Торакны бирү шартнамәсенә кул куя
Имзаланган торакны бирү шартнамәсе
Реестр бүлеге белгече,
Эш башкару бүлеге белгече
Реестр бүлеге белгече торакны бирү шартнамәсен терки, эш башкару бүлеге белгече торакны бирү шартнамәсен гариза бирүчегә юллый
Теркәлгән һәм гариза бирүчегә юлланган торакны бирү шартнамәсе

Россия Федерациясе гражданнарына үзләре били торган, Татарстан Республикасының казна мөлкәте булып торган торагын милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмәлек)

## Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр<br>Хамаев Азат Кыям улы | 221-40-00 | mzio@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары<br>Демидов Сергей Анатольевич | 221-40-02 | mzio@tatar.ru |
| Мөлкәт идарәсе башлыгы<br>Сафина Фәнисә Рәшит кызы | 221-40-25 | Fanisa.Safina@tatar.ru |
| Торак күчемсез мөлкәт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары бүлеге мөдире<br>Акаева Ольга Александровна | 221-40-28 | Olga.Akaeva@tatar.ru |
| Канцелярия эшләрен алып бару һәм контрольдә тоту бүлеге мөдире<br>Румянцева Гөлнур Нияз кызы | 221-40-81 | Gulnur.Rumyanceva@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгы<br>Нафигин Альберт Илдар улы | 264-77-22 | Albert.Nafigin@tatar.ru |
| Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгы урынбасары<br>Гайзатуллина Чулпан Нияз кызы | 264-77-90 | Chulpan.Gayzatullina@tatar.ru |